КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 октябрь г.Казань № 1026

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 - 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 03 февраль, 72 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләренә хосусый медицина оешмаларын 65 яшьтән өлкәнрәк һәм шул исәптән авыл җирендә яшәүче затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 22 сентябрендәге 1593 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 - 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 705 нче; 2021

ел, 11 февраль, 70 нче, 2021 ел, 24 май, 366 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2022 елда хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булып торучы, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, 65 яшьтән өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектында катнашу өчен хосусый медицина оешмаларын сайлап алу 2021 елның 1 декабренә кадәр гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган «2020 – 2024 елларда шәхси медицина оешмаларына – шәхси медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү кагыйдәләрендә:

15 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 елда хосусый медицина оешмаларын сайлап алуны уздырганда 2022 елда әлеге пунктның икенче - бишенче абзацларында күрсәтелгән гамәлләрнең пилот проектында катнашу өчен 2021 елның 30 ноябренә кадәр гамәлгә ашырыла.»;

18 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 елда хосусый медицина оешмаларын 2022 елда пилот проектында катнашу өчен сайлап алганда, әлеге пунктның җиденче абзацында күрсәтелгән комиссия карары 2021 елның 30 ноябренә кадәр кабул ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин